# ПЕНСИОНЕР ГАЗЕТАСЫ

№ 3 (69)
МАРТ
2023
Индексы
П 5248



*Пенсионерларга, инвалидларга, ятимнәргә кагылышлы законнар, социаль яклау һәм төрле ташламалар турында мәгълүмат, салымнар өлкәсендәге яңалыклар, гайбәт-гыйбрәт һәм файдалы киңәшләр. Һәртөрле котлаулар, игъланнар бушлай кабул ителә.*

***Картлык - зур шатлык дип беләм мин.***
***Картайган саен яшәүнең тәме арта бара.***
**Заһид МӘХМҮДИ.**

Айга бер тапкыр чыга
16+

podpiska.pochta.ru




## БУ САНДА НИЛӘР БАР:


- Сез безгә комачаулыйсыз! *4 бит*
- КАЯ ТАБА ТӘГӘРИБЕЗ? *5-6 битләр*
- Кушканны эт эшләр, үзе белеп адәм эшләр *10-11 битләр*
- РӘНҖЕШ *Сагышларым, сары сагышларым, Язылгандыр инде язмышыма...* *12-15 битләр*



# Пенсионерлар игътибарына



## Социаль пенсияләрне өстәмә рәвештә индексацияләячәкләр

Россиядә 1 апрельдән социаль пенсияләрне өстәмә рәвештә 3,3 процентка индексацияләячәкләр. РФ Хөкүмәтенең шул хактагы карары хокукый мәгълүмат интернет-порталында урнаштырылган.

"Россия Федерациясе Хөкүмәте 2023 елның 1 апреленнән социаль пенсияләрнең индексация коэффициентын 1,033 күләмендә раслау турында карар чыгара", - диелә документта.

Индексация күләме узган елда пенсионерларның яшәү минимумы арту темпларыннан чыгып исәпләнә. Социаль түләүләр чирагында ул елына бер тапкыр - 1 апрельдә үткәрелә.

2023 елның 1 гыйнварыннан яшәү минимумы 3,3 процентка артты, хәзер ул 14 375 сум тәшкил итә. 2022 елның апрелендә социаль пенсияне план нигезендә - 8,6, июльдә планнан тыш тагын 10 процентка индексацияләделәр. Социаль түләүләрне этаплап арттыру Хөкүмәтнең бәяләр күтәрелүнең тискәре нәтиҗәләрен киметү теләге белән бәйле.

Плеханов исемендәге РЭУНЫҢ "кеше ресурслары белән идарә итү" сәүдә-сәнәгать палатасы кафедрасы доценты Людмила Иванова-Швец сүзләренчә, узган елның көзендә 3,5 миллионга якын россияле социаль пенсия алган.

Аның искәртүенчә, аны нинди дә булса сәбәпләр аркасында картлык буенча иминият пенсиясенә акча тупламаган кешеләр ала. Шулай ук социаль пенсия инвалидларга һәм туендыручысын югалткан яки ата-анасыз калган балаларга бирелә.

Социаль пенсия дәүләт тарафыннан ярдәм булып тора, дигән эксперт.

*("Татар-информ")*

## Газеталарга 2023 елның беренче ярты еллыгына әле дә язылып була!



**Өч айга язылу бәяләре түбәндәгечә:**

**"СЕБЕРКЕ"**
Татарстан буенча - 405 сум;
Регионнар буенча - 501 сумнан алып.

**"СЕРЕМНЕ СИҢА ЧИШӘМ"**
Татарстан буенча - 363 сум;
Регионнар буенча - 441 сумнан алып.

**"ЯЗМЫШЛАР"**
Татарстан буенча - 272 сум;
Регионнар буенча - 321 сумнан алып.

**"ПЕНСИОНЕР ГАЗЕТАСЫ"**
Татарстан буенча - 149 сум;
Регионнар буенча - 183 сумнан алып.

**"КҮРКӘМ ХАТЫН", "ГАЙБӘТЧЕ", "БЕРГЕНӘМ-БЕРДӘНБЕРЕМ"**
Татарстан буенча - 165 сум;
Регионнар буенча - 201 сумнан алып.

**"МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ"**
Татарстан буенча - 253 сум.

* * * * * * * * * * * * * * * * * * * * * * *

**"Себерке"** - айга 4 тапкыр, 32 битле булып, атналык телепрограмма белән чыга. **Индексы - П 2496.**

**"Серемне сиңа чишәм"** - айга 4 тапкыр чыга, **индексы - П 2505.**

**"Язмышлар"** - айга 2 тапкыр чыга, **индексы - П 2687.**

**"Пенсионер газетасы", индексы - П 5248.**

**"Күркәм хатын", индексы - П 5249.**

**"Гайбәтче", индексы - П 5251.**

**"Бергенәм-бердәнберем", индексы - П 5250.**

**"Мәхәббәт һәм нәфрәт" - Индексы - ПА909.**

podpiska.pochta.ru

## СССР, РФ Геройларына пособиене заявка бирмичә түләү тәртибе турында закон кабул ителде



Дәүләт Думасы Советлар Союзы һәм Россия Геройларына айлык акчалата пособиене заявка бирмичә түләү тәртибе турында закон кабул итте. Бу хакта "Российская газета" яза.

"Геройлар үз тормышлары бәрабәренә илебез көчле, имин булсын өчен барысын да эшли, аларның гаиләләре үзләренә тиешле түләүләрне бернинди тоткарлыксыз, заявка бирмичә алырга тиеш", - дип искәртте Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин.

Күрсәтелгән категорияләрне айлык түләүләрне алу өчен заявка бирү һәм кирәкле документлар тәкъдим итүдән азат итәчәкләр.

Депутатлар шулай ук индексациядән соң мондый түләүләрнең күләменә төгәллек кертте. Әйтик, Геройлар яки Дан орденының тулы кавалерларына түләүләр - 83 мең 496,41 сум, Социалистик Хезмәт Геройлары, Хезмәт Геройлары һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына 61 мең 566,28 сум күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта, гражданнарга акчалата түләү һәм натураль ташламалар (азык-төлек, өс һәм аяк киемнәре яки дарулар рәвешендәге ярдәм) арасыннан берсен сайлау мөмкинлеге бирелә. Мөрәҗәгатьләр телефон, электрон почта яки Дәүләт хезмәтләре порталы аша кабул ителә.

## Рецепт белән бирелә торган даруларны дистанцион сату тәртибе

1 марттан Россиядә рецепт белән бирелә торган даруларны дистанцион сату буенча эксперимент башлана. Премьер-министр Михаил Мишустин аны үткәрү тәртибен раслады.

Эксперимент Мәскәү шәһәре, Мәскәү һәм Белгород өлкәләрендә башлана һәм 2026 елның 1 мартына кадәр дәвам итәчәк.

Анда үз сайты булган яки маркетплейс белән килешү төзегән даруханәләр катнаша ала. Аларның шулай ук формалаштырылган заказларны саклау өчен бүлмәсе, температура режимы үтәлә торган махсус бокслар кулланып, даруларны сатучыларга үз вакытында илтеп бирү мөмкинлеге булырга тиеш. Эксперимент ирекле нигездә узачак.

Элегрәк Сәламәтлек саклау министрлыгы онлайн-сатуга рөхсәт ителгән дарулар исемлеген раслаган иде. Анда антибиотиклар, шикәр диабеты, гипертензия, бронхиаль астма һ.б. авыруларны дәвалаганда кулланыла торган препаратлар керә. Составында наркотик, психотроп яки көчле тәэсир итә торган матдәләр булган, этил спирты күләме 25 проценттан артып киткән препаратларны сату тыела.

## Даруны рецептсыз саткан өчен штраф күләме арттырылачак

Дәүләт Думасы даруларны рецептсыз саткан өчен штрафларны арттыру турында закон проектын кабул итәргә ниятли.

Документта әйтелгәнчә, штраф күләме фармацевтика хезмәткәрләре һәм вазыйфаи затлар өчен - 10 мең сумнан 20 мең сумга кадәр (яки 6 айдан 1 елга кадәр дисквалификация), хосусый эшмәкәрләр өчен - 50 меңнән 100 мең сумга кадәр, юридик затлар өчен - 150 меңнән 200 мең сумга кадәр тәшкил итәчәк.

Сәламәтлек саклау, Дәүләт төзелеше һәм законнар чыгару комитетлары, аны I укылышта кабул итәргә тәкъдим итеп, закон проектына уңай бәяләмәләр биргән.

Закон проекты авторлары, яңа нормалар кертү зарурилыгын "дару наркоманиясе" үсүгә бәйләп аңлата. 2010 елдан бирле ул 2,5 тапкыр арткан. Бигрәк тә үсмерләр һәм яшьләр арасында киң таралган бу афәт алга таба аларны тагын да көчлерәк наркотикларга күчүгә китерә, дигән фикердә парламентчылар.

*("Татар-информ")*

podpiska.pochta.ru



# Сез безгә комачаулыйсыз!

Чиләге белән җиләк сатып торучыларны күрсәм, хәтеремдә бер күренеш яңара. Инде шактый еллар узса да, ул әбинең яңаклары буйлап агып төшкән ике тамчы яше һаман күз алдымда. Ямьле җәйге иртә. Шәһәр урамнарын әле генә юдырып киткәннәр. Юл читендәге күлдәвектә күгәрченнәр рәхәтләнә - су коеналар. Чәчәк таҗларындагы чык тамчысында - кояш нуры!

Мин, бәләкәй кызымны җитәкләп, базар буйлап киләм. Әлегә халык аз. Сатучылар өлгер үзе: тауарларын тезеп куярга да җитешкән. Юлым җиләк-җимеш рәте аша. Алма-әфлисун, өрек-күрәгә сатучыларның монда хуҗа икәнлеге әллә каян күренеп тора - урыннары түрдә. Сатып торучы кызлары үзебезнеке булса да, тауарлары читтән кайткан. Хуҗа тиешле кешеләр дә чит халык. Болар алдына икенче рәт булып үзләре үстергән нигъмәтләр белән сату итүчеләр тезелешкән. Арырак - кай арада пешкән диген - чиләкләп җиләк саталар. Аякларым ирексездән шулар ягына таба атлады.

Җиләкчеләр күп түгел, өч-дүрт кенә бөртек. Авыл апалары! Һәркайсының алдында җиләк белән тулы икешәр-өчәр чиләк. Рәтнең иң кырыена чәчәкле ситса күлмәкле, ак батист яулыгын таратып бәйләгән бер апа да елышкан. Аның да алдында ике чиләк. Бу апаны күрүгә, йөрәк сулкылдап куйды: яше белән дә, киенүе белән дә нәкъ дәү әниемә охшаган. Ул да шундый бәләкәй генә гәүдәле иде. Аның да бәйләгән яулыклары ак, кигән күлмәкләре чәчәкле иде. Безнең дәү әни бу яшьтә җиләк җыеп йөри алмый иде инде. Бу апа үзе җыйды микәнни бу тиклем җиләкне?

Янында тукталуымны күреп, җиләк алырга ниятли дип уйлады булса кирәк, нәкъ минем дәү әниемчә, йомшак итеп:

- Кызым, җиләгем бик эре. Көтү кайткач кына җыеп төштек. Ал, кызым, - дип, җиләген мактап куйды.

- И-и, апа! Мин үзем дә авылныкы бит. Җиләкне без үзебез җыябыз, - дип әйтергә авызымны гына ачкан идем, түрдәге сәүдә рәтеннән таза бәдәнле ике егет атылып чыкмасынмы!

Ни булганын аңларга да өлгермәдек, акырабакыра йөгереп тә килделәр, әбекәйнең бер чиләген тибеп тә аудардылар. Аяк астына кып-кызыл җиләк чәчелде. Ак яулыклы әбием, аһ итеп, икенче чиләгенә капланды. Юк, кычкырмады, беркемне дә ачуланмады ул. Аның җилдән кипшергән иреннәре фәкать бер сүзне кабатлады:

- Чү, улым, чү!

Җиләкчеләр дә, башкалар да бермәл аптырашка калдык. Ни булды? Нигә әбине рәнҗетә бу егетләр? Ул беркемгә дә начарлык кылмады бит! Барыбызга да әби алдында бик уңайсыз булып китте.

Кемдер чиләген китереп бирде, кемдер рәнҗетүчеләргә нәгъръләр орырга тотынды. Бәләкәй кызым җирдә чәчелеп яткан җиләкләрнең берничәсен әбинең чиләгенә китереп салды да, кыяр-кыймас кына, аның кул аркасын сыйпап куйды. Үзенчә юатмакчы була. Ак яулыклы мөлаем әбекәйнең яңаклары буйлап ике күзеннән ике тамчы яшь тәгәрәп төште. Базар гөр килде:

- Нинди хәл бу? Нәрсә, безгә монда сатарга да ярамыймыни?!

Теге егетләр дә, белмим, әллә таҗик, әллә әрмәннәр иде алар, күкрәкне нык киергәннәр.

- Без монда урын өчен акча түлибез. Сез безгә комачаулыйсыз. Бик сатасыгыз килсә, базар кырыенда торыгыз, - дип, авыл апаларын пыранлатып куа башладылар.

Бу ниткән башбаштаклык! Бу әбинең әтисе, туганнары сугышта кан койган, бәлки әле, башын да салгандыр. Әнисе, илнең тамагын туйдыру өчен, көне-төне колхозда бил бөккәндер. Ул үзе дә кечкенәдән авыр эшкә җигелгәндер. Ник аның маңгай тире тамган шушы җирдә хәләл көче белән җыйган ике чиләк җиләген сатарга да хакы юк? Ник соң безнең базарларда килмешәкләр күкрәк киереп, үз таләпләрен куеп, хуҗа булып йөри. Алар яшәгән җиргә барып, аларның аналарын шулай рәнҗетеп кара син - шундук ботыңны сугып сындырачаклар, исән калуың да икеле әле. Ә безне, безнең чал чәчле апаларыбызны кем яклар?

Өмет-ышаныч белән күп бала тәрбияләп үстерүче никадәр гаилә фатирсыз тилмерә, ә үз иленнән качып киткән француз артистына бүләк ителгән фатирларның чуты юк. Әллә кайсы илләрнең миллиардлаган доллар әҗәтләре кичерелә, ә бер мескеннең, утка түләмәгән өчен, электр чыбыкларын кисәләр. Дәүләт безнең өч тиен бурычны да кичерми. Нигә болай кадерсез соң без?

**Лилия.**

podpiska.pochta.ru

# КАЯ ТАБА ТӘГӘРИБЕЗ?



Мәһиәсма апаның төпчеге - Физәлиясе - тумыштан ук сәламәтлеккә туймады. Ә бит ата белән ананың малай булыр, дип көтеп алган алтынчы сабыйлары иде ул. Жиде яшькә кадәр теле ачылмады кызның. Алай да рәхәтләнеп сөйләшә ала торган булмады. Физәлиягә кайбер хәрефләрне әйтүе авыр булды, шунлыктан сүзләре дә аңлашылып бетмәде. Тора-бара кызның акыл ягы да сау түгел икәнлеге ачыкланды. Физәлияне мәктәпкә укырга кабул итмәделәр. Тугыз яшендә кыз балага инвалидлык төркеме бирделәр.

Мәһиәсма апа үзе дә олы яшьтә булгач, бала белән тиешенчә шөгыльләнергә, дәвалану курслары узарга әллә ни атлыгып тормады. Югыйсә, әллә нинди шифаханәләргә бару мөмкинлеге бар иде. Шул рәвешле, Физәлия әти-әни канаты астында үсте, өйдә аңа эшче кул итеп кенә карадылар. Чөнки эштән башканы белмәде: ашарга-мазар әзерләмәсә дә, абзар тулы мал-туар, тавык-чебешләр, каз-үрдәкләр аның өстендә булды.

Таңнан торып ике сыер савып, аларны көтүгә озатканнан сон, бакчага чыгып китәр иде. Көянтә-чиләк белән су ташып, өй тирәсен бер кат барлап чыккач, урам тутырып бибиләрне су буена алып төшәр иде. Көтү кайтыр алдыннан шул бибиләрне янәдән җыеп, алып кайтып җиткергәнче тагын берәр сәгать вакыт уза. Кичке савымнан соң кыз капка төбенә чыгып утырып, яшьләрнең клубка чыгып киткәннәрен күзәтә, ләкин аларга ияргә кыймый.

Уенын-чынын бергә кушып, авыл яшьләре әллә ничә мәртәбә кичке биюгә дәшеп карадылар аны.

Юк дигәнне аңлатып, башын селкүдән ары узмады ул. Физәлиянең көне менә шул рәвешле уза да китә иде.

Кызның апалары бер-бер артлы кияүгә китеп таралышкач, карт әти-әнисенә бердәнбер юаныч, иптәш булып калды Физәлия. Акылга туймаса да, бар тормышны тартты, җигелеп эшләде ул.

Берәүнең дә гомере мәңгелек түгел. Ике ел аерма белән әти-әниләре бакыйлыкка күчкәч, Физәлиянең апалары авыл ягына эзне суытты.

Кечкенәдән кулы эш белеп үскән кыз, бернидән куркып калмады. Ялгызлыктан ул көнелен малларына бушатты, шулар белән юанды.

Ярый әле колхоз рәисе салампечәнен, фуражын биреп торды, башка ярдәмнәреннән дә ташламады. Кыз бәрәңге бакчасын да кул белән казып, кул белән утыртты. Авыл халкы аның бөтен җаны-тәне белән эшкә бирелүен күреп, тел шартлатты, сокланып карады. Әйе, мыскыллап көлүчеләр дә житәрлек иде. Төнлә бакчасына кереп алма-чияләрен урлап чыгулар, кыяр түтәлен пыран-заран китерүләр дисеңме...

...Узган ел Физәлиягә район үзәгендә фатир бирәләр икән дигән сүз таралды. Сәламәтлекләре чикле, тәрбияләүчеләре булмаганнарга бирелергә тиеш фатир инде ул.

Кайлардан гына ишеткәннәр, ничек кенә белгәннәр диегез әле сез: Физәлиянең апалары, бер-бер артлы, күчтәнәчләрен төяп кайта башламасыннармы?! Әле берсе, әле икенчесе: “Малларыңны сатабыз да, сине үзебезгә алып китәбез, фатирыбыз иркен”, - дип юмалый башлаганнар моны.

Физәлиянең башлары катып беткән, болай да күп нәрсәгә башы эшләп бетерми инде аның. Алып китәбез дигәч, бик куанган үзе. Аның бит гомерендә бер тапкыр да авылдан читкә чыгып караганы юк. Иң ерак дигәне шул кибет тә, авыл башындагы ферма инде.

*(Дәвамы 6 нчы биттә)*



podpisnaya-pochta.ru

# КАЯ ТАБА ТӘГӘРИБЕЗ?

*(Дәвамы. Башы 5 нче биттә)*

Сыер савучылар янына барып, шулар белән сөйләшкән булып, вакытын уздырып йөри Физәлия.

Менә берзаман, Физәлиянең биш апасы берьюлы кайтып төшеп, кара тавыш чыгарды. Сеңелләрен бүлешә алмадылар. Аларны, барыннан да бигрәк, фатир кызыктыра иде.

Иң олы апалары Тәүхилә арада иң өлгере дә булып чыкты: әллә нинди документлар ясатып, Физәлияне үз карамагына тәрбиягә алуны рәсмиләштергән. Сыерларын сатып, тавык-казларын суеп, тәки сеңлесен үзе янына шәһәргә алып китте бит Тәүхилә.

Ике атнадан янә авылга кайтып төште болар. Физәлия, авылны сагынып, кире кайтаруларын сораган икән. Шулай шул: кунак беренче өч көндә генә кадерле, аннан соң кадерең китә. Кышын тагын Физәлия Тәүхилә апасына яшәргә китте.

Дөресрәге, аны мәҗбүриләп, газларын өздереп киттеләр. “Бу юлы күпме азаплап тотарлар икән бичараны”, - дип артларыннан зар елап калучылар да күп иде. Язын чирәм шыта башлагач кына авылга кайтардылар Физәлияне.

Тәүхиләнең йөзендә язгы кояш нурлары “сикергәләп” тора иде. Ник дисәгез, ул үз дигәненә ирешкән: районүзәктәге фатирны үз исеменә рәсмиләштергән. Шуннан соң, ягъни җинел генә сеңлесенең өлешен үзләштергәч, Физәлиягә көн бетте. Атлаган саен кунакка алып китүләр үткәндә калды.

Авылдагы үле тынлыкка байтак ияләшә алмады Физәлия. Өзлексез каңгылдап торган казлары, үзе янына чыкырып мөгрәгән сыеры да юк бит аның хәзер. Алты почмаклы зур бүрәнә йортта япа-ялгызы калды...

Шуны гына көткәндәй, ысылдап, икенче апасы кайтып төште. “Нәрсә, ярык тагарак артында утырып калдыңмы? Безне читкә этәреп, Тәүхилә апаны сайлаган идең, нинди рәхәт күрсәтте ул сиңа?” - дип Физәлиянең болай да яралы йөрәген тагын меңгә телде. Анысы да әйтеп торган була тагын, Тәүхиләгә үзләренең көче җиттеме соң?! Әнә, эшне кызу тоткан анысы: теге фатирга кеше кертеп, акча эшләү җаен да тапкан олы апалары. Алты бала арасында иң нык тормышлы, житештә яшәүчесе шул Тәүхилә бит югыйсә. Күрәсең, мал күп булган саен җитми.

Ни генә дисәң дә, акча ничек җиңел керсә, шулай ук чыгып та китә. Кемнендер күз яшьләре белән табылган мал бәрәкәт китерми. Үзем күрмәдем, гөнаһысына керү булмасын, әмма авыл халкы: “Салам өеме кадәр Тәүхиләдән сәнәк сабы гына калган, бик ябыккан, чирли икән”, - дип сөйли. Таякка таянып, көч-хәл белән өйгә кереп киткәнен күреп калучылар булган. Саулыгы какшагач, авылга да кайтканы юк ди. Физәлиядән бу турыда сорашкан идем, ул анык кына берни әйтә алмады. Өзек-өзек сүзләреннән Тәүхиләне каядыр еракка киткән икән дип аңладым. Ерак җир дигәне хастаханәмазар түгел микән әле. Менә мәйтәм, фатир бәһасен чыгарып түләсән дә сәламәтлекне кире кайтарып булмый. Туганлык җепләрен киредән ныгыту турында әйтеп тә тормыйм.

Болай да акылы сау булмаган Физәлия, бүгенге көндә кая барып сугылырга белмичә, авылда яшәп тора. Әле ярый мәш килергә зур бакчасы бар. Китәм, апайларга торырга барам, дип тә сөйләнә икән. Кайсы апасы үз канаты астына сыендырыр ул бичараны?

Тәүхиләнең комсызлыгы аркасында башка апалары Физәлиягә үпкәләде. Ә Тәүхиләнең үзен тәрбияләргә кеше кирәк булуы бар. Уйламыйча эш итсән, менә шундый хәлдә калуың да мөмкин.

Ә иң борчыганы шул: Физәлия алга таба нишләр? Аның да яше бара, саулыгы какшый, бик үк сәламәт булмагач, болай да үз яшеннән күпкә олы күренә ул. Инде хәзер апалары төп нигез өчен тарткалаша башламасалар ярый. Ул очракта сеңелләренең бөтенләй урамда торып калуы бар, Аллам сакласын.

Физәлия кебек язмышка дучар булучылар арабызда бихисап. Ветераннарга бирелгән фатир өчен сугышып яшәүче гаиләләр, бертуганнар җитәрлек. Алар турында газета битләрендә генә укып шаккатмыйбыз, күз алдыбызда бит. Кая таба тәгәрибез? Иң якын кешеләребез белән дошманлашып, көнләшеп, туганлыкны онытып көн итү яшәү рәвешебезгә әйләнеп бара түгелме? Кыргый җәнлекләр дә бер-берсенә ташланмыйлар. Ә без алардан да түбән булып чыгабыз түгелме соң?!

**Раушания МИННЕБАЕВА.**

## Белү зыян итмәс

### Дөрес куллану шарт

*Бер төр даруларны озак кабул итүнең хәвефе турында табиб-гастроэнтеролог Рөстәм Садыйков хәбәр итте. Сүз ашказаны җәрәхәтеннән, рефлюкс-эзофагит, гастропатиядән җәфаланучыларга билгеләнә торган омепразол, лансопразол, пантопразол, рабепразол һәм эзомепразол турында бара.*

*Бу препаратлар ашказан-эчәк трактында тоз кислотасы продукциясен киметә. Пациентлар бу даруларны еш кына үзаллы билгелиләр һәм еллар буе эчәләр. Бу ашказанда кислоталылык дәрәҗәсе кимү, ашкайнату процессының начараюы һәм бактериаль авырулар барлыкка килү белән яный, дип кисәтә Садыйков.*

*Белгеч бу төр даруларны кабул итү кагыйдәләрен санап үтте. Аларны ашарга 30-60 минут кала 12 атнадан да артмаган курс дәвамында эчәргә кирәк.*

**Искәрмә: табиб белән киңәшләшү зарур.**

podpiska.pochta.ru

Аллаһ юлы - нурлы юл

# Йөрәгебез - иман урыны

Хәзерге вакытта без күбрәк үзебезнең тышкы кыяфәтебезгә игътибар бирәбез. Тәнне чыныктырабыз, ашатабыз, эчертәбез, матур киемнәр кидерәбез, өй төзибез, машина алабыз һәм башкалар. Пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи үә сәлләм әйткән: "Аллаһы Тәгалә сезнең төс-кыяфәтләрегезгә һәм мал-мөлкәтләрегезгә карамый, Ул сезнең калеб-күңелләрегезгә һәм кылган эшләрегезгә карый".

Безнең йөрәгебез - ул иман урыны. Шуның өчен иман телдә, колакта, язуда гына түгел, ә йөрәктә булырга тиеш. Кеше мәет булгач, аның каберенә Мөнкәр белән Нәкир исемле фәрештәләр килеп, сорау алачаклар. Ул кеше тел һәм акыл белән сөйли алмас, ә йөрәк белән җавап кайтарыр.

Аллаһның илчесе Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән: "Дөреслектә, тәндә бер ит кисәге бар, ул сәламәт булса бөтен тән сәламәт була, ул авырса, бөтен тән чирләр. Дөреслектә ул әгъза - йөрәк".

Без тәнне чиста тотабыз, фатирыбызны идән суырткычы белән ялт итәбез, киемнәребезне кер юу машинасында пакьлыйбыз, машинаны да махсус җиргә алып барып юабыз. Безнең йөрәгебез дә пакьлануга мохтаҗ. Йөрәккә дүрт юл тоташа: күзләр, колаклар, тел һәм уй. Шушы дүрт әгъзаны хәрам әйбәрләрдән сакларга кирәк. Берсеннән булса да йөрәккә хәрам керсә, йөрәк карала башлый. Күз алдына бассейны китерик. Ана дүрт краннан су килә. Берсеннән булса да пычрак су керсә, бөтен бассейндагы су пычракка әйләнәчәк. Ә йөрәгебезгә барган юлларны ничек чиста тотарга була? Аллаһ бар иткән дөньяга карап фикерләргә, Коръән китабын укырга, колаклар белән вәгазь тыңларга, тел белән Раббыбызны даими истә тотарга кирәк.

Шулай ук, кайчан кеше гөнаһларны кылып, аның йөрәге каралык белән капланса, алар тышка чыгып, тәндә авыруны барлыкка китерә. Рәсүл Әкрам галәйһиссәләм әйткән: "Кеше гөнаһ кылгач, аның йөрәгендә кара нокта барлыкка килә. Әгәр ул тәүбә итмәсә, ул кара нокта шунда кала. Ә инде тагын гөнаһ кылуны дәвам итсә, аның бөтен йөрәге каралык белән капланыр".

Кешеләрнең тормышына карасаң, бөтенесе дә бар шикелле, ләкин аларның йөрәкләрендә тынычсызлык һәм булганына ризасызлык күренә. Хәдис кодсидә Аллаһы Тәгалә әйткән: "Я Адәм баласы, Миңа гыйбадәт кылу өчен вакытны тап! Мин синең йөрәгеңнән тынычсызлыкны алырмын һәм фәкыйрьлектән имин кылырмын. Әгәр шулай эшләмәсәң, синең йөрәгеңне борчулар белән тутырырмын һәм син фәкыйрьлектә калачаксың!"

Бу хәдистән чыгып, шуны аңларга була: фәкать Аллаһка гыйбадәт кылу белән, Аны истә тотып, йөрәкләребез тынычланыр. Мисал итеп, кайнаган сулы савытка, бераз салкын су өстәсәк, ул кайнаудан туктар. Шулай ук, бу дөнья артыннан куган вакытта, аны бер мизгел эчендә читкә куеп, намаз үтәүгә, Коръән укуга, зикер кылуга йөрәгебезне юнәлтсәк, безгә шундый рәхәтлек, җиңеллек киләчәк.

Расулуллаһ салләллаһү галәйһи үә сәлләм әйткән: "Тимер суда ничек күгәрә, шулай ук йөрәкләрегез тутыга!" Берсе: "Я Расулуллаһ галәйһиссәләм, йөрәкне ничек пакьларга була?" - дип сорый. Ул галәйһиссәләм: "Үлемне еш искә алу һәм Коръәнне уку белән!" - дип җавап бирә.

Безнең бу дөньяда яшәвебезнең максаты - ул йөрәгебезне пакьлыкта, чисталыкта тоту. Ничек без чиста йөрәк белән якты дөньяга килдек, шулай ук ахирәткә күчкәндә, Аллаһы Тәгалә каршына басканда пакь йөрәк белән барырга тиешбез.

Ни өчен сәхабәләргә безгә караганда дин тоту җиңел булган? Чөнки аларның йөрәгендә дин, ә кулында дөнья булган. Ә безнең киресенчә: йөрәгебездә - дөнья, ә кулыбызда дин тора. Шуның өчен дин тоту безгә авыр булып тоела.

Рәсүл Әкрам галәйһиссәләм: "Кыямәт көне алдыннан, дин тоту янган күмер кисәге кебек булыр. Тотсаң пешерер, җибәрсәң сүнәр", - дип әйткән. Минем хатын, минем балалар, минем өем, минем машинам, минем эшем, дип сөйләргә яратабыз. Ә кешегә тагын "Минем динем!" дип гадәткә кертеп, яратып әйтергә өйрәнергә кирәк. Ничек без хатын, балалар, эш өчен җаваплы, шулай ук дин өчен без барыбыз да җаваплыбыз.

Бал хакында, аның файдасы, тәме турында никадәр сөйләсәк тә, ашамыйча торып, боларны белеп булмый. Шулай ук суга кермичә торып, йөзәргә өйрәнә алмыйбыз. Моннан чыгып, шуны аңлыйбыз: динне аңлар өчен, аның буенча яшәргә кирәк.

Йөрәк - ул тәндәге патша кебек. Ничек патша кешеләргә әмер кылып эшләтә, шулай ук йөрәк тән әгъзалары белән идарә итә. Йөрәк кара булса, аның теленнән начар сүзләр чыга, күзләре яман әйберләргә карый, уй белән оятсызлык хакында хыяллана, колаклар әшәкелекне тыңлый. Ә ничек йөрәкне каралыктан пакьларга?

Пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһисәләм шундый дога кылган: "Аллаһүммә мусаррифәл кулүүб сарриф кулүүбәнәә галәә таагәтик (Йөрәкләребезне юнәлдерүче, йә Аллаһ, Синең буйсынуына безнең йөрәкләребезне юнәлт). Йә мукаллибәл кулүүб сәббит калбии галәә дииник (Йә йөрәгебезнең халәтен үзгәртүче, Синең динеңә йөрәгемне нык кыл)".

**Ибраһим хәзрәт ШАҺИМӘРДӘНОВ.**

podpiska.pochta.ru

# Сукыр скрипкачы

Авылдан Айбулатның бабасы Сафиулла карт кунакка килгән иде. Бабасының күчтәнәчләр төяп килеп төшүе Айбулат өчен бер бәйрәмгә әверелде. Анысы, Айбулат күчтәнәчләргә кызыкмый, тәмле әйберләргә аның мохтаҗлыгы юк, аңа бабасы кадерлерәк, аңа Казан урамында бабасы белән йөрү тансык. Кичке табын янында авыл күчтәнәчләреннән авыз итеп, хәл-әхвәл сорашып утыргач, йокларга әзерләнделәр: бабасы шулай соңга калып килеп төшкән иде. Айбулатның әбисе белән бабасы еракта яши - башта тимер юл станциясенә кадәр машинада килергә кирәк, аннары поездга күчеп утырасы. Авылдан иртүк чыгып китсән дә, Казанга төнлә генә килеп җитәсең...

Рита аларның өчесенә дә - Айбулатка да, Мансурга да, Сафиулла картка да урынны залга җәйде. Болай итүе бик әйбәт булды: Сафиулла карт, арып килдем, дисә дә, ярты төн узганчы улы Мансур белән гәпләшеп ята, әллә нинди кызыклы тарихлар сөйли. Айбулатка рәхәт: юрганга төренеп, бабасы сөйләгән кыйссаларны тыңлый.

Бу килүендә дә Айбулат өчен шактый кызыклы әңгәмә башланып китте. Утны сүндергәннәр иде инде, Мансур мендәрдән башын калкытты да:

- Хәтерлисеңме, әти, мин бала чакта авылга сукыр скрипкачы килгән иде?.. - дип сорады.

- Беләм, минем таныш иде ул... - диде Сафиулла карт. - Оста скрипкачы иде, шәп уйный иде.

- Менә шул турыда синнән сорарга теләгән дә идем инде, - диде Мансур. - Шуның язмышы кызыксындыра мине...

- Озын тарих ул, сөйләсәң, әллә кайларга кереп китәргә туры килер... Мин үз гомеремдә сукыр скрипкачыларны аз күрмәдем. Безнең авылга да бик еш килә торганнар иде. Кайберләре, акча җыю нияте белән, юри дә сукырга салынып йөрделәр инде. Син әйткәне шул булса...

- Менә болай, - дип, аны бүлдерде Мансур. - Безнең авылга мин бала чакта ике сукыр скрипкачы килгәнен беләм. Кайсы еллар икәнен хәтерләмим. Икесе ике кеше булдымы алар, әллә икесе дә бер кешеме?.. Тик менә берсенең бездә кунып чыкканлыгын беләм. Сез аның белән келәттә икәү бергә йокладыгыз... Ни сөйләшкәнсездер - анысы миңа караңгы.

- Әйе, әйе, - дип, җанланып китте Сафиулла карт, хәтта торып ук утырды. - Алайса, син минем танышны әйтәсең инде. Таныш кынамы соң, минем җан дустым иде ул! Әй, гомерләр!.. Кара, мин аны картлыгым белән онытa да язганмын инде. Ярый әле хәтергә төшердең.

- Каян танышлар идегез соң сез, әти?

- Без бит Алабуга культура-агарту училищесында бергә укып алган идек. Озак түгел инде. Шул ярты ел, бер ел чамасыдыр. Тумышы белән Минзәлә якларыннан иде ул. Авылының исемен хәтерләмим инде, исемнән чыккан. Менә шул. Бездә кунып чыккан булса, әнә шул скрипкачы инде ул.

Мансур торып утырды, утны кабызды, китап шкафыннан нидер караштырды, янә утны сүндерде.

- Тумыштан сукыр булмагандыр ич ул, әти? Училищеда да укырлык булгач, дип әйтүем?

- Юк инде, нишләп сукыр булсын?! Сау-сәламәт егет иде. Харап иттеләр шул...

- Ничек харап иттеләр?

- Сталинның культ чоры башлангач... Укып беләсеңдер, ул чакта кешене төрмәгә тыгу берни дә тормый иде. Ике-өч кеше берләшеп, бер кеше өстеннән шикаять язып бирсәләр - беттең исәплә.

- Шулай да сәбәпсез эшләнмәгәндер ләбаса? Шикаять язып бирүчесе дә тиктомалга андый юлга басмас.

- Тиктомалдан түгел. Бер дә тиктомалдан түгел. Көнчелек хәрәкәткә китерә андый шикаятьчеләрне, көнчелек! Бу егеттән дә берничә малай бик каты көнләшкән.

Бабасы белән әтисенең әңгәмәсе бигүк аңлашылып бетмәсә дә, Айбулатка куркыныч була башлады. Юрганына ныграк төренде. Тәрәзәдән балкыган айны алып китәрләр кебек тоелды. Хәзер, менә шушы төн уртасында, фатир ишеген каерып ачарлар да, өйгә таныш түгел кешеләр килеп керер кебек иде. Сталин чоры турында өлкәннәрдән ишетеп белә: куркыныч булган ул чакларда.

- Алар бер үк авылдан бер егет, бер кыз - икәүләшеп укырга килеп кергәннәр иде, - дип сүзен дәвам итте Сафиулла карт. - Авылда күршеләр генә булып яшәгәннәр. Сабый чакта бергә уйнап үскәннәр, бер мәктәптә бергә укыганнар. Инде үсеп җиткәч, егет кызны нык яраткан, авыл кешеләре арасында яманатлары чыгудан да курыкмыйча, кызый белән күрешкәләгән... Моны ул соңыннан, теге чакны келәттә йоклаганда, сөйләп ятты. Күрешү - күрешү, аны нихәтле генә яшерергә тырышсаң да, йомып калып булмый, каһәр. Монда да шулай була: кызның әтисе белән әнисе сизенеп ала, егетне кисәтәләр. Шуннан нишләргә кала инде: тулы булмаган урта мәктәпне тәмамлагач, егет белән кыз авылдан китәргә, берәр шәһәргә барып, укуларын дәвам итәргә сүз куешалар.

Егет скрипкада бик оста уйнаса, кыз матур итеп җырлый икән. Райкомолда боларга Алабуга шәһәрендәге культура-агарту училищесына барып карарга киңәш итәләр. Әнә шул киңәш белән алар училищега килеп керделәр. Менә бу кыз да, мескенкәй, әти-әнисенең сүзен тыңлап кияүгә чыккан булса, бәлки, исән дә калыр иде әле...

- Нишләде? - дип шомланып сорады Мансур. - Үлдеме? Үтерделәрме?

- Үлде дисәң дә, дөреслеккә туры килми инде, - дип, тамагын кырып алды Сафиулла карт. - Үтерүен үтермәделәр, үз-үзенә кул салырга

podpiska.pochta.ru

мәҗбүр иттеләр. Болай булган. Безнең анда сталинчы бер төркем малай бар иде. Шул малайларның берсе әлеге кызга кызыккан, үзенеке итәсе килгән. Шәхес культы чорында кешенең котын алып каршыңа тезләндерү җиңел эш иде. Бу малай да, иптәшләре белән сүз берләшеп, теге кызны комсомол комитетына чакыртып керткәннәр. “Менә шулай-шулай, әтиеңнең халык дошманы булуы ачыкланды, - дигәннәр. - Өлкәдән кәгазь килеп төште, - дигәннәр. - Сине эзлиләр”, - дигәннәр.

- Ах, кабахәтләр, - диде Мансур, тешләрен шыгырдатып. - Кара нинди җиңел юл тапканнар, ә?!

- Берсе әйткән: “Син әтиеңне дә, үзеңне дә бәладән коткара аласың. Мин сиңа юлын өйрәтәм, - дигән. - Безнең сүзне тыңласаң, барысы да ал да гөл булачак”, - дигән. Кызыйның андый гөнаһка барасы килмәгән... Тулай торагындагы ятагында язу калдырган да юкка чыккан.

- Анда нәрсә дип язды икән? - дип, кызыксынып сорады Мансур.

- Анда ул болайрак дип язган: “Минем әтиемнең халык дошманы булуын ачыклаганнар. Әтием халык дошманы булгач, Совет җәмгыятендә үземне яшәргә лаек дип саный алмыйм, суга батып үләм. Хушыгыз!” - дигән. Язуның табылуын барыбыз да белеп алдык, кызыйны эзләргә чыгып киттек. Декабрь ае, чатнама суык. Камада боз каткан чак. Күз алдыма китерсәм, хәзер дә тәннәрем чымырдап китә. Төркем белән елга өстеннән карга батачума бер шәүләнең йөгергәнен шәйләп алдык. Андый чакта була бит ул: качкан кеше, куркытылган кеше сине коткарырга киләләр дип белми, киресенчә, артыннан эзәрлекли чыкканнар дип белә. Без кычкырабыз тегеңә, ул аның саен йөгерә. Тавыш юньләп ишетелерлек ара түгел инде, шактый еракта...

- Теге малайлар котын алганнар инде… - дип куйды Мансур.

- Алмыймы соң инде!.. - Сафиулла карт суны аз-азлап кына кабып эчеп куйды. - Кыз балага җитә кала инде. Житмәсә, авыл баласы бит әле ул, кем нәрсә әйтсә, шуңа ышана. Теге малайлар әйткәннең дөреслеген тикшереп тору кая ул?! Аннары, тәкъдимнәреңә дә күнә алмый инде: безнең халыкта кызлык намусын саклау бик көчле бит… Намусын пычраттымы - ул инде кеше арасында яшәргә яраксыз исәпләнә. Белмим, хәзер ничектер, элек шулай иде. Мин хәзерге яшьләрне белмим. Аннары, безнең заманда шәригать кануннары да халыкны бик нык тәрбияли торган иде шул. Калганын иртәгә сөйләшеп бетерербез, яме, бүгенгә җитеп торыр.

- Иртәгә ял көне, беребезнең дә эшкә барасы юк, - диде әңгәмәне өзәргә теләмәгән Мансур.

- Кама уртасындарак балыкчылар ачкан бәке булган икән. Кызыбызны инде куып җиттек дигәндә генә, бәкегә төште дә китте… - дип, кыйссасын ялгап җибәрде Сафиулла карт. - Барыбыз да “аһ” иттек!.. Кем уйлаган аны шулай кыланыр дип?! Кем уйлаган анда бәке бардыр дип?! Кирәк бит инде, әй… Инде куып җиттек, инде тоттык дигәндә генә бит… Шундук таш кебек аска китте, иелеп карадык - киемнәре белән акрын гына су төбенә төшеп бара. Әй, кызганыч та соң, әй, шул кызны кызгануыбыз! Теге скрипкачы дустыбыз, тартып чыгарам мин аны дип, бишмәтен үк сала башлады. “Нишлисең, тиле?!” - дибез. “Әллә синең дә су төбенә ычкынасың киләме?!” - дибез. “Миңа ансыз яшәү юк! Мин аны коткарырга тиеш!” - дип кычкыра. Бер малайның кесәсендә бавы булган икән, шуның бер очын биленә урап, бозлы суга төшереп җибәрдек инде. Кая ул тартып чыгару?! Менә шулай итеп, миңа коточкыч хәлнең шаһиты булырга туры килде.

- Ай-яй, - дип уфылдап куйды Мансур. - Моны тыңласаң гына да чәчләр үрә тора.

- Үлгән артыннан үлеп булмый, дигәндәй, егетне дә харап итәсебез килмәде, боз өстенә тартып чыгардык, җылы киемнәргә төрдек, тулай торакка алып кайтып, тәнен спирт белән уып карадык - тик файдасыз иде - салкын тиеп өлгергән... Шактый вакыт авырып ятты. Савыккач, кызы өчен үч алырга теләп, теге малайларга бәйләнә башлаган. Аңамы соң иблис токымнарына каршы тора алу... “Комсомол безгә кирәкми, ул оешманы таркатырга кирәк!” - дип сөйләнеп йөри дигән ялган яла яктылар да төрмәгә озаттылар.

- Кайда сукырайган соң ул? - дип сорады Мансур.

- Себердә концлагерьда булган, шунда тагын салкын тигергән. Илле алтынчы елда гына аңа туган якларына кайтып егылырга насыйп булган. Менә шундый заманнар бар иде, улым.

- Бик гыйбрәтле тарих бу, әти, - диде Мансур. - Мин язучы булсам, һичшиксез, моны утырып язар идем. Кызганыч, язучы булмаганмын.

- Минем дустым гомере буе сөйгән кызына тугрылыклы булып калды. Скрипкада ул үзенең кызының гүзәллеген, сафлыгын уйный иде, үзләренең фаҗигале мәхәббәтен скрипка моңнары аша сөйләп бирә торган иде...

Мансур сикереп торды да өстәл лампасын кабызды.

- Әти! Шәп әйттең! - дип, шатланып кычкырып җибәрде ул. - Таптым, таптым!

- Нәрсәне таптың, улым? - дип, Сафиулла карт та торып утырды. Айбулат та, күзләрен угалый-угалый, әтисе янына барып басты.

- Карале, әти, кыз калдырган язуда теге егетләрнең таләпләре әйтелгән идеме икән? - дип кызыксынды Мансур.

- Әйтелгән иде, - диде Сафиулла карт.

- Мин моны картина итеп ясаячакмын! - дип дәртләнде Мансур.

- Шул картныймы?

- Картны гына түгел, әти! Рәсем сәнгатенең мөмкинлекләре чиксез бит. Барысын да сыйдырам, барысын да…

- Ай-һай… - дип, шик белдерде Сафиулла карт. - Белмим инде, булдыра алсаң, кара шунда.

- Булдырабыз аны, әти!

**Хәйдәр.**

podpiska.pochta.ru



# Кушканны эт ашар, үзе белән адәм ашар

Башкалада яшәгән балаларына уйламаган җирдән җыенырга туры килде Тәрҗемә апага. Исәбе-уенда да юк иде, энесенең хатыны көчләп диярлек күндерде. “Әйдә, әзер машинага утырып бар, бер-ике көн йортыңа күрше-күлән дә күз-колак булып торыр, сыерыңның да ташлаткан чагы”, - дигәч, ризалашты. Улы белән килененең кайткан саен: “Әнкәй, фатир котлатканнан бирле безгә килгәнең дә юк”, - дип үпкәләбрәк әйткәннәре дә гел күңелен кырып торды. Чынлап та, ике ел вакыт үтеп киткән, ләбаса. Үзләре еш кайтып йөргәч ни, сизелми дә икән вакытның узганы.

Кичтән балаларына кәрәзле телефоннан шылтыратып, кунакка киләсен әйткәч, Тәрҗемә апа алып барасы күчтәнәчләрен хәстәрләргә кереште. Ике олы сумканы тутырып, веранда ягына чыгарып куйгач: “Барысын да салдыммы, тагын берәр нәрсә онытылып калмады микән?” - дип сөйләнә-сөйләнә, урын җәяргә кереште. Касыймы үлгәннән бирле, түрдәге йокы бүлмәсендә ятмый ул. “Бәләкәй як” дип йөртелгән бүлмәдәге диванда йоклый. Җылырак та, уңайлырак та кебек тоела үзенә. Бәлки, сагыну, юксыну хисләрен җиңәргә тырышуы гынадыр, кем белсен! Кырык ел кырык көн генә түгел бит. Бер тән, бер җан иткән ястыкка ялгызың килеп ятулары, айһай, җиңел түгел икән! Көндезләре көндәлек мәшәкатьләр белән үтсә дә, кичкә кергәч, ялгызлык сиздерә. Әле дә ярый, Илсур улы башкалада калды. Әнә, кызларын өйләнешү белән ирләре Себергә алып чыгып киттеләр. Барысы да шунда агылганда, безнекеләрне генә тыеп калып буламыни?

Илсур улы йортка тузан төшерми, шөкер. Килененнән дә унды Тәрҗемә апа. Гүзәлиянен, авыл кызы булмаса да, бөтен эшкә кулы килешеп тора. Хәер, үзе дә иркәләнеп, аларның кайтып эш бетергәнен көтеп тормый. Ял йортыннан кайтмыйлар ич алар. Улы - заводта инженер, килене - табибә. Атна буе әллә арымыйлар, дисеңме? Юк, Тәрҗемә апа өлгергән кадәр, көче җиткәнчә йорттагы эшләрен үзе эшли. Күмәк көч сораганнары гына кала. Пенсиядәге кешенең кабаланып ашыгыр җире юк, тазалыктан гына аермасын Ходай. Аннан килеп, балаларына сөтен-каймагын, бәрәңгесуганын биреп җибәрүләре үзе бер күңеллелек, рәхәтлек бит! “Әнкәй, без кайтканда булса да утырып тор”, - дигән балаларын: “Тик торсаң, сөяк тутыга, тик торганчы каткан туныңны уа тор”, - дип көлдереп алырга да ярата.

“Бер уйлана башласаң, уйларның очына чыгарлык түгел, иртәгә юлга чыгасы”, - дип, Тәрҗемә апа башка көннәргә караганда утын иртәрәк сүндереп, йокларга ятты.

Энеләре аны алырга кергәндә, җомга иртәсе беленә башлаган иде. Өч сәгать дигәндә калага килеп тә җиттеләр. Алдан сөйләшеп куйганча, улы подъезд янында каршы алды. “И-и-и, әнкәй, әллә күченеп килгәнсең инде”, - дип шаяртты Илсур, олы сумкалар белән лифтка кергәндә. Гүзәлия тиз генә табын өлгертте. Аның бүген икенче смена икән, тамак ялгап алганнан соң, ул эшкә җыена башлады. Илсур да әнисен каршы алырга гына кайткан булган. “Әнкәй, ачуланма инде, оныкларың кайтканчы бераз ялгызың утырырга туры килер”, - дип, Тәрҗемә апаны фатирда бикләп чыгып киттеләр.

Ике сәгатьтән оныклары кайткач, фатир эче җанланып китте. Башта алар бер-берсе белән ярышып, дәү әниләренә үзләренең яңалыкларын сөйләделәр. Аннан авыл күчтәнәчләре белән сыйлангач, өчәүләшеп якындагы паркта һава сулап керделәр. Оныклары дәресләрен карарга утыргач, Тәрҗемә апа аш-су бүлмәсенә чыкты. Улы белән килене эштән кайтуга пилмән бөгеп алырга уйлады. Авылдан иттарткычтан чыгарып, тәмләткечләрен салып алып кил-

гән итне суыткычның аскы өлешеннән алды. “Нәкъ вакыты, камыр басыйм”, - дип бисмилласын әйтеп, эшкә кереште. Соңгы пилмәннәрне ясаганда Илсур кайтып керде. Димәк, Гүзәлия дә озакламаячак. “Килен кайтканчы капкалап аласыңмы? Пилмәнне ул кайтугарак салырбызмы?” - дип сорады Тәрҗемә апа улыннан. “Көтик, ярты сәгатьтән кайтып житәчәк ул. Нигә мәшәкатьләнеп инде, әнкәй, Гүзәлия үзе әзерләр иде әле”, - дип, юыну бүлмәсеннән чыккач, залдагы телевизор каршысына килеп утырды.

- Бәй, киленнең эштән кайтып ашарга әзерләгәнен көтеп утырабызмы җыйнаулашып, язмаганны.

- Мин аш-су бүлмәсенә ашарга гына керәм.

- Начар, улым!

- Тукта, тукта, әнкәй, безнең әткәйнең чәй куйганын да хәтерләмим, алай дисәң.

Тәрҗемә апа улына бүген генә күргән кеше кебек карап куйды.

- Син арыш белән бодайны бутама, улым. Механизатор әткәгез белән ярышыр идеңме әллә? Аның кебек колхоз эшеннән кайткач, мал карасың, кар көрәсең, печән чабасың бармы? Хатының да синең кебек хөкүмәт эшенә йөри, гаиләгә акча китерә. Ул да бит кеше баласы, әнкәсе белән әткәсенең газизе!

Илсур дәшмәде. Уйлап карасаң, хак сүзләр. Тик моңа кадәр Гүзәлиясе аны савыт-саба юдырып, ашарга әзерләтеп җәфаламады, үзе барысына да өлгерде. Элегрәк келәм чистартыша иде, хәзер анысы да малайлар җилкәсендә. Дөрес, елларда авылга кайтмаганда азык-төлек кибетләренә бергә чыгалар, анысы. Атна уртасында кирәген Гүзәлия эштән кайтышлый үзе алып кайта.

- Авылда бер минут та тик утырмыйсың бит, улым, нишләп калада болай? - дип, “допрос”ын дәвам итте Тәрҗемә апа.

- И, әнкәй, авылда икенче инде, кала фатиры түгел. Син мине бөтенләй ялкау кешегә әйләндерден дә куйдың түгелме соң? Фатирдагы ир-ат эшлисе эшләрне үзем эшлим мин, мастер чакыртканым юк.

- Улым, ул яктан бер сүзем дә юк, алтын куллы икәнеңне беләм. Югары белемле инженер була торып та эшләмәсәң. Тик... Сез ир-атлар фатирда көн дә ачкыч тотып, нәрсә дә булса төзәтмисез, ә хатын-кызның көндәлек эше, авылныкымы ул, шәһәрнекеме, тавык чүпләсә дә бетәрлек түгел. Аны сиңа аңлатырга кирәкми, утызның теге ягына чыктың. Фатирыгыздагы чисталыктан күз камаша, өстәлдәге ризыклар телне йотарлык, үзеңнең дә, балаларның да киемнәре чук кебек, юылган, үтүкләнгән. Киленнән иртәрәк кайткан көннәрендә аш-су бүлмәсенә керергә өйрән, дип әйтүем. Бергә эшләгәндә аш та тәмле, өй дә ямьле! Студент чакларында ресторанда ашап йөргәнеңне хәтерләмим, үзебез әзерлибез, дип сөйли торган идең түгелме?

- Анысы шулай инде, әнкәй, үзебез әзерләп ашадык күп вакыт. Гүзәлия кушса, мин каршы килмим инде алай.

- “Кушканны эт эшләр, үзе белеп адәм эшләр”, дип халык юкка әйтмәгән улым, нәрсә әллә эт көненә төштеңме?

Тәрҗемә апа белән Илсурның сүзен звонок тавышы бүлде. Гүзәлиянең ишектән үткәч иң беренче сүзе: “Аh, нинди тәмле пилмән исе! Эштән кайтып кергәндә сине әзер ризык каршы алгач, нинди рәхәт!” - булды.

Кичке аштан соң, Илсур савыт-саба юарга әзерләнгән хатынына: “Без малайлар белән монда үзебез тәртип ясарбыз, сез әнкәй белән чөкердәшегез иркенләп”, - дип, биленә алъяпкыч салды. Тәрҗемә апа канәгать елмаеп, өстәл яныннан кузгалды.

**Люция ӘБЛИЕВА.**

## Озак яшим дисәң – ела!

Күз яшьләнүенең өч төре бар. Алар барысы да төрле максатларга хезмәт итә.

Беренчедән, күренмәгән күз яшьләре. Алар даими рәвештә күз яшьләнүе белән бәйле. Бактериягә каршы һәм күзләргә дымлылыкны сакларга булыша. Алар гадәти санда булганда, без аларны сизмибез дә.

Икенчедән, рефлектор күз яшьләре бар - нәкъ менә алар суган кискәндә, җилгә каршы барганда, яки безгә, әйтик, күзләргә берәр чит әйбер эләксә, нәкъ менә алар безнең күзләребездән елга кебек ага. Мондый күз яшьләрендә күп антитәнчекләр бар һәм организмның тышкы ярсыткычлардан һәм микроблардан саклану реакциясе булып тора.

Өченчедән, хисле күз яшьләре бар. Бу безнең позитив һәм тискәре тойгыларыбыз - авырту, шатлык яки сагыш, шуңа күрә без елаганда нәкъ менә шушы күз яшьләре барлыкка килә.

## Менә сиңа мә!

### Елау бик файдалы!

* Әгәр 15 минут буенча рәхәтләнеп елыйсың икән, бер ел буена җыелган киеренкелектән котылырга була.

* Кеше күзендә елына 4,5 литр тирәсе яшь ясала.

* Хатын-кызлар ирләргә караганда 5 тапкыр ешрак елый, шунлыктан ирләрдән 6-8 елга озаграк яши.

* Иң тозлы яшь - авыртудан яки чарасызлыктан акканы, суган чистартканда чыккан күз яшьләре төчерәк була икән.



* Иң сирәк елаучылар - Кытайда яшәүчеләр, иң еш елаучылар - америкалылар һәм Непал халкы.



podpiska.pochta.ru

# РӘНҖЕШ



Равиянең вафаты сәгате-минуты белән авылга таралды. Бу кайгылы хәбәрдән халык “аһ” итте. Һәркемнең телендә шушы вакыйгага бәйләнешле сүз.

- Һай, жаным, бигрәкләр дә жәл инде. Яшь бит... Яшь... Утыз биш яшеңнән кара җир асларына кереп ят инде...

- Оялары белән киттеләр бит инде! Равия - төпчекләре. Әллә алдан киткәннәре карт идеме?!

- Әй-й, - дип уфтанды күршеләре Миңзифа түти. - Әҗәлетдин яшеңне сорап тормый инде ул, ала да китә..

- Җәмәгать, Миңкамал әби рәнҗеше бу! Валлаһи, шулай! Рәнҗеш дигәнең җиде буынына кадәр җитә, ди бит!

Хатынның сүзләренә каршы әйтергә берәү дә базмады. Бу мәлдә Миңкамал әби язмышын күңелдән кичерделәр булса кирәк. Унынчы дистәне ваклый башлаган кортканың терлек абзарында вафат булуын, аны шунда юып кәфенләүләрен һәркем белә...

Миңкамал әбинең карты Сәмигулла абзый дөнья куйганда, бердәнбер уллары Габбас егерме өч яшендә иде. Чем кара бөдрә чәчле, түгәрәк йөзле, коңгырт күзле, базык гәүдәле Габбас эшкә урнашырга ашкынып тормый. Ни игенчелек, ни терлекчелек күңеленә ятмый. Шәһәр юлын таптый. Урманчылык эшенә дә тотынып карый. Тик төпләнеп, эшләп китә генә алмый.

Агач келәймәләп йөргән чагында бер кыз белән таныша ул. Әтисез, әнисез калып, балалар йортында тәрбияләнгән Хәнифә Габбасның тәкъдимен бер сүзсез кабул итә. Яшькелт-зәңгәрсу күзле, уртача буйлы, коңгырт чәчләре кыска итеп киселгән егерме яшьлек Хәнифә Миңкамал апа йортына килен булып төшә. Улының бу гамәлен әби яхшыга юрый. Кәҗәсенең игез бәтиләренең берсен суйдырып, никах укыта. Бер ай әйбәт кенә яшиләр, ике ай... Кайнана алар өчен сөенеп бетә алмый. Кая карама - улы белән килене гел бергә: абзарда да, тезмәдә дә... “И-и, мин дә ир белән торган инде, - дип куя ул эченнән генә. - Аллага шөкер, кайнанамны олылап яшәдем”, - дип тынычлана үзе. Бер-бер артлы ике ир бала тапкач, Хәнифәнең тавышы бөереннән чыга башлый. Габбас хәзер, хатыны янында, бертуктаусыз койрык болгап торган тугры эт шикелле... Әни кеше һаман үз эшендә: өй җыештыра, чишмәгә суга барып килә, ашарга пешерә... Бәрәңге әрчиәрчи, күңелендәге уйларын җыр сыман көйли:

*Анадыр - бәладер.*
*Арба артыннан барадыр,*
*Хатындыр - жандыр.*
*Янда утырып барадыр...*

Шулай бер көйгә яшәп торганда, 1940 ел да килеп җитте. Кояшлы март аеның бер көнендә авылга “Вербовщик килде. Читкә, еракка урман кисәргә кешеләр җыя икән”, дигән хәбәр таралды. Габбас бу форсаттан файдаланасы итте. Язылып, гаиләсе белән Себер якларына китеп барды.

Урамга каратып салынган, каршыдагы ике тәрәзә төбе менә-менә җиргә тиям дип торган иске йортта әби ялгыз калды. Хәзер ул эчендәге уйларын, “мыр-мыр” килеп йокларга яратучы, аклы-каралы песие белән уртаклаша. Кайвакыт серләрен чикләвек куагыннан үреп, сыер тизәге белән сыланган абзарда яшәүче ак кәҗәсенә сөйли:

- И, кәҗәкәем, кәҗәкәем, - дип яратып эндәшә ул аңа. - Язмыш миңа ялгызлык насыйп иткән, күрәсең. Картым да үлде, бердәнбер улым да китте... Ярый әле Мияубикә белән син бар... Әйдә, әйдә, син дә кырланып, ялындырып торма - аша. Өч кат юып пешердем мин ул бәрәңге кабыгын. - Миңкамал әби утын вакла-

podpiska.pochta.ru

ганда да, кәҗә абзарын җыештырганда да, шулай сөйләшә.

Яз җитте. "Бакчаны кем сукалап бирер икән, бәрәңгене ничекләр утыртырмын?" - дип борчыла башлады. Килеш-килбәте, кара-кучкыл түгәрәк йөзе белән һинд ирләренә охшаш Исмәгыйль:

- Борчылма, җиңги, - дип, җылы сүзен әйтте. - Исән чакта бер-беребезне ташламабыз.

Бәрәңге, суган ише яшелчәләрне утыртып бетерүгә матур җәй җитте. Ул матурлыкка карап хозурланырга авыл кешесенең вакыты гына юк. Өен җылытырга - утын, малына ашатырга печән җыясы бар. Ул арада бәрәңге буразналарын чүп үләне басып китә.

Миңкамал әби, һәркөн иртәнге якта, авылга якын гына гөрләп үсеп утырган әрәмәлеккә юл тота. Урагы белән кечкенә балтасын киндер капчыкка тыгып, арба әрҗәсенә бәйли дә, терек-терек үз юлында була. Сузып япкан яшел яулыгының, кара җирлеккә зәңгәр чәчәкләр төшерелгән алъяпкычының төсе күз кергәндә уңып бетә. Кайчандыр Сәмигулласы ясап биргән кул арбасының әрҗәсен иң элек корыган чикләвек куаклары, өрәңге ботаклары белән тутыра. Өскә яшел миллек яки сусыл печән җыеп сала.

Көз кереп, агач яфракларыннан җиргә сары юрган сырылгач та, Миңкамал әрәмәлек сукмагына тузан төшерми. Кәҗәкәе өчен яфрак җыя. Шулай яши-яши көн артыннан көн, ай артыннан ай уза. Һәм... 1941 елның матур июнь иртәсендә "Сугыш башланган!" дигән коточкыч хәбәр авыл өстен кара кайгы белән томалый.

Соңгы вакытта Габбастан хәбәр юк. "Исән микән? Сугышта йөри микән? Балалар, гаиләсе кайда икән?" Бу сорауларына Миңкамал җавап таба алмады.

Җәйләрне - көзләр, көзләрне кышлар алыштырды. Авылга аяксыз, кулсыз ирләр кайта башлады. Күпме кешегә кара кәгазь килде... Габбастан гына бер хәбәр дә юк. "Кайда улы? Исәнме? Хәле ничек икән?" - бу сораулар Миңкамалның уеннан бер генә мизгелгә дә чыкмады.

Миңкамал өметен өзмәде - көтте. Төнге җилләр тәрәзә пыяласына кагылса да, салам түбә ыңгырашып алса да, күрше эте өреп куйса да, ул торып утырды. Габбасы менә-менә кайтып җитәр дә ишек шакыр сыман тоелды аңа. Күңелендә йөрткән сагыну-сагышларын җырга салып, телендә тирбәтә:

*Сагышларым, сары сагышларым,*
*Язылгандыр инде язмышыма...*

Әллә күп елаудан, әллә өлкәнәйгән көнендә дә бертуктаусыз авыр тормыш йөген тартудан, әллә тормыш ярлылыгыннан Миңкамалның күзләре зәгыйфьләнә башлады. Күз алдында томан барлыкка килде. Аптырады ул бу хәлгә. Күрше-күлән киңәше белән чәй дә салып карады, кер сабыны белән дә юды, "зәңгәр-яшел" дигән таш белән күз кырыйларын сызды. Файдасы гына тимәде. Күз каршындагы томан куерганнан-куерды гына. Күршеләргә рәхмәт инде. Алар ташламады.

1949 елга кергәндә, әбинең сул күзе тәмам томаланды. Ә уны дөнья яктысын бераз шәйли, каршысына килеп баскан кешене бераз гына булса да чамалый.

Шушы елның апреле иде. Миңкамал күршесе белән төшке чәйне чәйләп алгач, бераз ял итеп алырга ният кылды. Маңгай күзләре зәгыйфьләнсә дә, урамдагы яз һавасын, кояшның мамыклы җылысын тоеп ята ул. Күңелдә челтерәп аккан гөрләвекләр, инеш ярларын тутырып аккан бозлар... Бу юлы ул яткан гына иде, җил капка шыгырдап ачылуын ишетеп алды.

"Кем булыр икән?" - дип уйлап алды әби, урыныннан тормыйча гына. Ул арада сөйләшкән тавышлар да ишетелде. "Әнеккәем, Габбасым түгелме соң бу?" - дип торып утырды Миңкамал.

Аның колагы ялгышмады. Ишек киң итеп ачылды да аннан биш малаен, хатынын ияртеп, улы килеп керде. Сөенеченнән Миңкамалның тез буыннары йомшарып китте.

- Улы-ы-ым! - диде ул, сәкесендә утырган хәлендә ике кулын сузып. Кайттыңмы... Аллага шөкер, бу көннәрне дә күрдем... - дип, Габбасының күкрәгенә капланды.

Моннан туып киткән ике малай инде буй җиткән. Артларыннан, әнә, тагын өчәү үсеп килә. Җиде кешедән торган зур гаилә әбинең кечкенә генә өенә кереп урнашты. Миңкамалга сәкедә урын калмады: песие Мияубикә белән бергә, мич башына күченде... Күрше-күлән, бер күрешеп чыккач, Миңкамал янына кереп йөрмәде диярлек, сирәкләде. Кечкенә генә йорт, зур гаилә... Кеше уңайсызлап, борчып йөрүне килештермәделәр.

Миңкамал үзе таягына таянып, Исмәгыйльләргә кергәләде. Кайбер көннәрне кунып та калгалады. Соңгы вакытта аның күңеленә әллә ни булды: ул үзенең гомер иткән йортында утырып торырдай урын таба алмый. Өйдәгеләр үзара урысча сөйләшә. Колакка ятышсыз шау-шу, тәмәке төтене исе... Берәү дә хәлен сорашмый. Хәер, сирәк-мирәк булса да, кайчакта Габбас: "Әни, берәр әйбер кирәкмиме?" - дип, үтешли генә сорап куя.

Июнь ае иде бугай. Хәнифә килен сөтле чәй бирми башлады. Бер көнне ул: "Килен, кәҗә буазмы, ташландымы әллә?" - дип дәшеп тә караган иде - җавап кына булмады. Ә менә бу юлы җае чыкты, Габбас аңа үзе эндәште:

- Әни, берәр нәрсә кирәкмиме?
- Ә-ә, улым... Өйдә үзең генәме?

Бу сорауны ишетеп торган Хәнифә уң кулының имән бармагын иреннәренә куйды.

Хатынның ишарәсенә тиз төшенде ир:

- Үзем генә, - дип җавап бирде.
- Улым, сөтле чәй эчәсем килә. Килен никтер сөтле чәй бирми... - дип әйтмәкче булып Миңкамал сүз башлады. - Улым, киленгә әйт әле, сөтле чәй...

Шул арада Габбаска әллә ни булды, кинәт күкерттәй кабынды. Мич башында утырган әби каршысына очып диярлек килеп басты.

- Син нәрсә?! - дип акырып җибәрде ул, җөмләсенә урысча тәмсез сүз өстәп. - Минем хатынның кайсы җире ошамый! - Аның тәмсез теленнән кулы да калышмады. Габбас көрәктәй зур, көчле йодрыгын әнисенең яңагына кундырып алды.

(*Дәвамы 14-15 нче битләрдә*)



polpiska.pochta.ru

# РӘНҖЕШ

*(Дәвамы. Башы 12-13 нче битләрдә)*

Миңкамал мендәргә ауды. Аның элпә томалаган караңгы күз алдында яп-якты булып очкыннар гына чәчелеп калды. Ул бер кәлимә сүз әйтмәде. Мөлдерәмә кайнар күз яшьләре йөзенә сызылган тирән буразналардан мендәренә тәгәрәде.

Өй эче тынып калды. Кинәт бар тараф ямьсезләнеп, каралып калгандай булды. Шул мәлдә ишек ачылып китте дә Исмәгыйль килеп керде. Ул матур итеп сәлам биреп керсә дә, аңа җавап бирүче булмады. Өйнең ямен алып, җанда пычрак эз калдырып, ниндидер давыл узуына курше агай тиз төшенде. Ул туп-туры Миңкамалга эндәште:

- Җинги, сине чәйгә алмага кергән идем. Минем кортка коймак пешерә.

- Ә-ә, Исмәгыйль, рәхмәт инде, рәхмәт... - диде Миңкамал, күз төпләрен калтыранган куллары белән сөртә-сөртә...

- Рәхмәт соңыннан, җинги, соңыннан… Әйе... Әйдә әле, ярдәм итим.

Исмәгыйль Миңкамалның терсәгеннән тотып, мич башыннан төшәргә ярдәм итте дә ишеккә таба атлады. Кечкенә өй эчендә аның тыны беткәндәй, сулышы кысылгандай булды. Шуңа күрә Миңкамалны җитәкләп алды да тизрәк чыгып китү ягын карады.

Габбасның ни өчен кабынып китүен Миңкамал чәй янында төшенде. Улы кәҗәне сатып, он алган икән...

Сөтле чәй эчәсе килүен әйтергә теләгән өчен Габбасның әнисенә кул күтәрүен ишеткәч, Исмәгыйль түзмәде - атылып күршеләренә керде.

- Оятсыз! - диде ул, ишектән керә-керешкә үк. - Оятсыз! Ничек көчең җитте?!

Һәй-й, адәм актыгы! Шушы яшенә җитеп ни кырдың соң син? Сугыш вакытында Тайгада качып яттың да, сугыш беткәч, кайттың! Яшь чагында да дүләли сугып йөрдең! Хәзер дә әнкәңнең кәҗәсен сатып, тамак туйдырасың... Ни чәчсәң - шуны урырсың, ди борынгылар. Биш малаең барын онытма! Берәрсе үзеңнән үрнәк алып үссә, нишләрсең?!

Исмәгыйль әрнүле сүзләрен әйтте-әйтте дә хатынына сыенып, сәкедә утырган Габбаска “Һә-әй!” - дип, кулын селтәп чыгып китте.

Ул җәйне Миңкамал әби өенә аяк басмады. Аны алмага керүче дә булмады...

Тормыш синең күңелеңдә ниләр барлыгы белән кызыксынмый, ага да ага. Габбасларның түр тәрәзәләреннән караганда, кояш көн дә Акъяр тавы артыннан күтәрелә. Аннары ул басу-кырларны, урман-суларны алтын нурлары белән коендыра-коендыра Ташкичү үзәненә таба йөзә. Яшел сусыл печәнле үзәнлектән соң, Коры Елга тавына да ерак калмый. Кояшның “бишеге” шунда: тау артындагы ерак офыкта алсу тасма сузылган җирдә.

Бөек серләр хәзинәсе тулы сихри йолдызларын җемелдәтеп төннең канат җәяр чагы җитә. Бу күренеш - табигатьнең катгый кануны. Адәм баласы моңа игътибар да итми: ул үз яшәеше белән мәшгуль.

Габбасның олы улы Бәдретдин тракторчы булырга укып кайтты да МТСта эшли башлады. Бәдретдиннән кече ике малай - Гали белән Вәли, шәһәргә китеп, ташчылар әзерли торган училищега укырга керде. Бәдретдин югары оч Рәсимәсенә өйләнде. Яшьләр җиң сызганып эшли башлагач, тормышлары да тернәкләнеп китте. Ниһаять, 1955 елның язында Миңкамал әбинең нигезендә яңа йорт калыкты.

Яңа йортка күчәр көннәр житкәч кенә, Хәнифә Габбаска болай дип әйтеп куйды:

- Кара әле, карткаем, әнине кая куярбыз икән?

Габбас аптырап, сорау тулы күзләрен хатынына төбәде.

- Ничек инде “кая куябыз”?

Иренең чыраенда чагылыш алган канәгатьсезлекне күреп, Хәнифә сүзен җайлап кына дәвам итте:

- Гел уйлап йөрим. Әни бик җәл: үзе сукыр, үзе карт. Менә бүген, менә иртәгә китәме дип, куркып торам...

- Соң! Күпме гомере бар - шуны яшәр!

- Мәсьәләнең икенче ягы бар бит: беләсең килсә, яңа йорттан мәет чыкканны яратмыйлар...

- Син нишләргә кушасың соң миңа? - дип аптырады ир.

- Әнинең дим, ятагын... абзарга гына куйсак, дим... Кәҗә бүлмәсе буш бит... Хәзер җәй... җылы... Сәке ясарсың...

Габбас бу тәкъдимгә ни дип тә җавап бирә алмады. Иркә-назга юмарт Хәнифәгә каршы әйтердәй сүз тапмады Габбас.

Миңкамалны элек кәҗәсе яшәгән абзарга урнаштырдылар...

Чикләвек куагыннан үрелгән, аралары сыер тизәге белән сыланган читән абзар ташландык бер салкын алачыкны хәтерләтә иде. Эштән кайткач, мал-туар караганда, яшь килен Рәсимә әбинең урынын йомшарта, туңмасын дип, өстенә үзенең бишмәтен ябып китә торган булды.

Габбаска бу гамәл ошап бетмәсә дә, Хәнифәнең: “Яңа өйдән мәет чыкса, артыннан мәетләр күп була икән”, - дигән сүзләрен искә алып, үз-үзен юатырга тырышты. Мал-туар арасында йөргәндә, әнисенең хәлен белгәләп тә чыккалады.

Бер көнне Миңкамал әби аның кулын учына алып сыйпап куйды:

- Улым, - диде Миңкамал йомшак кына итеп. - Кулың салкынча, көн үзгәргәндер. Киленгә әйт әле, мичкә күбрәк итеп яксын. Әллә нәрсәгә гел туңам...

Габбас әнисенең учыннан әкрен генә кулын алды да көч-хәл белән “ярар” дигән сүзне авызыннан төртеп чыгарды. Кинәт ирнең тамагына төер утырды. Ул авыр сулап, бүкәнгә чүкте дә

podpiska.pochta.ru

гомерендә беренче тапкыр күз яшьләренә ирек куйды...

Минкамал әби шушы җәйне дөнья куйды. Теле беткәнче үз акылын җуймаган сукыр әбинең күнелендә ниләр булды икән? Җырлы, моңлы җаны гомеренең сагышларын эченнән генә көйләде микән? Моны берәү дә белми. Ул аларның һәммәсен үзе белән алып китте...

Әнисен озатканнан соң, Габбас, кәҗә бүлмәсенә үзе ясап куйган сәкедә озаклап утыра торган булды...

Өйдә иркен сулыш алучы бердәнбер кеше Хәнифә булгандыр. Әмма киң сулышлы бу иркенлек озакка сузылмады. Әбинең мәңгелеккә китүенә бер ел дигәндә, яна йортның бусагасыннан коточкыч кара кайгы атлап керде: Габбас белән Хәнифәнең иң яраткан төпчек уллары - Газизҗан янып үлде.

Малай, абыйларыннан күреп, тәмәке тартырга өйрәнде. Баштарак ул өлкәннәрдән калган төпчекләрне суыргалады. Аннары инде тегеләрнең кесәләрендәге тәмәкене чәлдерә башлады. Аңа өй тирәсендә тартырга ярамый: күрсәләр - эләгәчәк. Шуңа күрә ул көн саен инеш аръягындагы әрәмәлеккә чыга. Анда иркенләп, агач төбенә утыра. Тәмәке төтенен өлкәннәргә охшатып, борын тишекләреннән чыгара. Утыра-утыра никотиннан исереп йоклап та китә.

Бу юлы учак яккан. Ялкын телләренең җилдә җилферди-җилферди уйнаклавын күзәтеп, махорка тәмәкесен суыргандыр. Һәм никотиннан исереп йоклап та киткән, күрәсең...

Әрәмәлек арасыннан күтәрелгән куе төтенне иң элек урамдагы бала-чага абайлый. "Әйдә әле, барып карыйк, нинди төтен икән?" - дип, үзара сөйләшә-сөйләшә әрәмәлеккә китәләр. Алар килеп җиткәндә, учак уты тирә-юньдәге куакларга үрләгән. Янәшәдә күмерләнгән учакка тәрәлгән гәүдә - Газизҗан гәүдәсе.

Бу коточкыч авыр кайгыны Габбасның таштай каты йөрәге дә күтәрә алмады... Ул түшәккә ауды. Шул ятудан көчле-көрле ир аякка басып китә алмады, авырый башлавына алты ай тула дигәндә, фани дөньядан китеп барды...

Өр-яңа йорт эчен җан өшеткеч салкынлык, кара кайгы пәрдә каплады.

Бер ел эчендә - өч мәет...

Хәнифәгә гомер сәгате тукталгандай тоелды. Өй эче тып-тын. Берәү дә кычкырып сөйләшми. Бу халәт мәңге бетмәс, бу караңгы салкынлык мәңге таралмас сыман тоела. Шушы рәвешле, яңа йортның яктылыгын, иркенлеген тоя алмыйча, җаны куаныч эчендә йөзә алмыйча ике еллап яшәгәч, Хәнифә дә мәңгелеккә күчте...

Ел артыннан ел үтте. Кояш көн саен Акъяр тавы артыннан күтәрелде дә Ташкичү үзәнлегенә таба юл тотты. Сихри, бөек серләр саклаган йолдызларын күккә сибеп, көн артыннан төн килде. Минкамал әби йөргән сукмакларны әллә ничә тапкыр язгы сулар юды. Хәзер инде авылда әбине хәтерләүчеләр дә бик аздыр. Ул үзе дә, исеме дә күптән онытылган иде инде...

Равиянең вафатын ишетүгә, өлкәннәр, әбинең фаҗигасен искә төшерде. Искә алмыйча мөмкин дә булмагандыр... Уйласаң, уелыплар китәсең... Бу нигезгә килгән фаҗигаләрне акылга сыйдырырлык түгел...

Бәдретдин белән Рәсимә берсеннән-берсе чибәр, берсеннән-берсе эшчән дүрт кыз үстерде. Кызларны үстереп, башлы-күзле итүгә ир белән хатын бер-бер артлы бу дөньядан китеп барды. Әти-әнисеннән соң, кечкенә ике баласын ятим калдырып, өлкән кыз Мәдинә китеп барды. Яман шеш диделәр. Берничә ел үтүгә Казанда шәфкать туташы булып эшләүче икенче кыз Галияне авылга алып кайтып җирләделәр. Аннары район үзәгендәге мәктәптә тарих укытучысы - өченче кыз Рамилә дөнья куйды. Рамиләне озатканга биш еллап вакыт узган иде инде... Кинәт җаннарны тетрәтеп, башларны иңрәтеп, авылга кайгылы хәбәр таралды - Равия вафат! Башлангыч сыйныфлар укытучысы, балаларның яраткан апалары...

Равияне җирләп кайткач та, күршеләре Минзифа апаның уенда гел шушы гаилә булды. "Рәнҗеш, рәнҗеш, - дип кабатлады ул үзалдына. - Җиде буынга кадәр җитүе хак миканни? Кырылдылар бит, ә... Печән пакусы шикелле бер-бер артлы аудылар... Бу балаларның ни гаебе бар инде?"

Минзифа җанына уралган шөбһәле уйларыннан арынырга теләгәндәй, тәрәзә янына килеп, урамга карады. Минкамал әбинең нигезе урам аркылы гына - нәкъ алар каршында. Пәрдәләре төшерелгән тәрәзәләре кояш чыгышына карый. Алар шундый моңсу: мөлдерәмә яшь белән тулган күзләр сыман. Әйтерсең лә, карашын ерак-еракка төбәп, Минкамал әби карап тора.

Берөзлексез күзләреннән түгелүче сагышмоңнары дулкын-дулкын булып, эңгер элпәседәй, чиксезлеккә тарала. Ирексездән әллә ул дулкыннар күкнең җиденче каты дигән урынга ук барып ирешә микән дип уйлап куясың.

Үзеннән-үзе тел әбинең җырын әкрен генә кабатлый:

*Анадыр - бәладер,*
*Арба артыннан барадыр...*
*Барадыр... Барадыр...*

**Сәйдә ЗЫЯЛЫ.**

## Кызынып калыгыз

Март ахырындагы-апрель башындагы кояшлы көннәр - җиңелчә кызыну, ләкин янмау өчен иң яхшы вакыт. Мона кар да ярдәм итә.

Безгә кояш өстән дә, астан да яктырта. Җәй көне мондый булмаячак. Чөнки җир энергияне тулысынча диярлек үзенә сендерә һәм аны чагылдырмый, ди белгечләр.

Кояшлы көннәр язда күп булачак. Әмма кар эри башлагач, кояш нурлары азрак чагылачак. Аннан инде җәйге кояш астында кызынырга кала. Ләкин аның зыянын да онытырга ярамый.

polniska-pochta.ru

# Хезмәте каты - җимеше татлы

## Кыярның мул уңыш бирә торган сортын үстерегез



Бүген кибет киштәләрендә нинди генә орлык юк: күзләр камаша. Хаклары да төрле. Әлбәттә, кайсын алырга да белмисең. Кыйммәтле орлык алып та, уңышсыз калган еллар була. Кайбер бакчачылар үзләре орлык эшләп калдыра. Бу очракта 2-3 ел сакланган кыяр орлыгына өстенлек бирергә кирәк. Бер еллык кыяр орлыгыннан, гадәттә, буш чәчәкләр генә җыеп алырга була.

Кыярның иң уңышлы сортларын тәкъдим итәбез:

"Зозуля F1". 1 квадрат метрдан 20 килограммга кадәр уңыш алып була. Кыярлары 300 грамм тирәсе, озынлыкка 22-24 сантиметр.

"Мурашка F1". Иртә уңыш бирүче гибрид. Теплицада 1 квадрат метрда 12 килограммга кадәр уңыш бирә. Кыярлары 12 сантиметр тирәсе.

"Сибирская гирлянда F1". Бер төптән 15тән 30 килограммга кадәр уңыш алырга була. Кыярлары артык зур түгел, тәмле.

"Емеля F1". 1 квадрат метрда 16 килограммга кадәр уңыш бирә. Теплицада, парникта, балконда аеруча яхшы үсә.

"Матрица F1". Иртә уңыш бирүче сорт, утыртканнан соң бер айдан тәүге яшелчәләрдән авыз итәргә мөмкин. Кыярның бу сорты теплица өчен.

Бакчачылар тагын "Маша", "Герман", "Московский деликатес", "Маринда F1", "Кураж", "Эколь F1" сортларын да яратып үстерә.

## Бакча яме - канәфер!

Бу искиткеч матур чәчәкне бакчасында бер үстереп караган кешеләр аннан аерыла алмыйдыр, мөгаен. Төрек канәференең (турецкая гвоздика) "Джолт Пинк F1" дип аталган сорты бик үзенчәлекле һәм башкаларыннан аерылып тора.

Чагу матур чәчәкле яңа канәфер гибриды җәй дәвамында шау чәчәктә утыра һәм аны үстерүе дә артык мәшәкать тудырмый.

Ул бик озак вакыт чәчәктә утыруы белән бакчачыларны сокландыра. Канәфер чәчәгенең башка төрләренә караганда, бу сорты нәкъ 4 атнага озаграк, хәтта кар төшкәнче шау чәчәктә утыра! Чәчәкләре чагу алсу төстә, алар кызгылт, шәмәхә һәм сары чәчәк түтәлләрендә аеруча матур күренә.

Шунысы мөһим, бу сорт начар һава торышына бик чыдам.

"Джолт Пинк F1" сортының биеклеге 30 сантиметрга җитә. Аларны бакчадагы алгы планга утырту отышлы. Яфраклары сусыл, куе яшел төстә. Чәчәкләре дә, яфраклары да төсләре белән бер-берсен тулыландырып торуы бик сирәк күренеш. Шуна күрә канәфер чәчәгенең бу сортын кечкенә кашполарга яки контейнерларга утыртырга да мөмкин, анда ул ялгызы гына да матур күренәчәк!

Бу чәчәкне үстерүе артык мәшәкатьле дә түгел. Әгәр мартта орлыкларын утыртсаң, ул июньдә чәчәк атачак.

Орлыклары бер сантиметр тирәнлектә күмелә һәм пленка белән каплана. Көненә бер-ике тапкыр пленканы ачып, җилләтергә кирәк булачак. Үсентеләре якынча ике атна эчендә күренә башлый, алар 5-6 чын яфрак чыгаргач кына күчереп утыртырга ярый. Төрек канәферен тәрбияләү башка үсемлекләрдән әллә ни аерылмый. Бу - туфракны йомшарту, атнага 1-2 тапкыр су сибү, ашлама кертү. Әлеге чәчәкне җинелчә күләгә төшкән урында үстерү яхшырак. "Джолт Пинк F1" сорты бакчагызны җәй буенча чәчәк дулкынына күмеп утырачак. Аның матурлыгын күрәсегез килсә, бүгеннән эшкә тотыныгыз.



podpiska.pochta.ru

**Баш мөхәррир:**
**Мәхмүтева Гүзәл Раузит кызы**
***Тел.: 89631392376;***
***Хатлар бүлеге:***
***8 (843) 523-41-35***
***Эл. почта: seberke@mail.ru***

**Редакция һәм нәшрият адресы: 420100, Казан шәһәре, Академик Глушко урамы, 8 йорт, 280 бүлмә (баш офис); 420066, Казан, Бондаренко урамы 24 йорт, 77 бүлмә.**

**Гамәлгә куючы: Гүзәл Рәүзит кызы Мәхмүтева**
**Нәшер итүче: ИП Махмутова Г.Р.**
**Газета 2017 елның 26 декабрендә Роскомнадзор тарафыннан теркәлде. Теркәү таныклыгы ПИ№ФС 77-71992**
**Татарстан каталогындагы индексы - П 5248.**
**АДРЕС: г.Казань ул. Ак. Глушко, д. 8-280**
**ОГРНИП 311169021700152 ОТ 05.08.2011г.**
**ИНН 165122333656**
**р/сч. 40802810262000010191**
**в ПАО «Сбербанк России»**
**кор/сч. 30101810300000000603**
**БИК 049205603**
**Махмутова Гузель Раузитовна.**

**Газетадагы язмаларның эчтәлеге өчен авторлар үзләре җаваплы.**
**Язмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
**Газетадан язмаларны күчереп бастырганда рәсми рөхсәт булу сорала.**
**«Манзара» нәшрият-полиграфия комплексында басылды. (Казан шәһәре, Бондаренко урамы, 24 йорт, 77 бүлмә.)**
**Газетага тираж сертификаты бирелгән.**
**Кәгазь форматы А4, күләме 2 басма табак.**
**Газетаның басылып чыгу вакыты: 23.03.2023 ел, 8:00 сәг.**

4 623721 598135

**Заказ № 1672**
**Гомуми тираж 3000**
**Сату бәясе ирекле.**